**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирү дәүләт мәгариф оешмалары студентларына дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирү дәүләт мәгариф оешмалары студентларына дәүләт ярдәмен көчәйтү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирү дәүләт мәгариф оешмалары студентларына дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» 2010 елның 21 декабрендәге ПУ-835 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 4 июнендәге ПУ-522 номерлы, 2019 елның 27 августындагы ПУ-504 номерлы һәм 2020 елның 17 гыйнварындагы ПУ-15 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирү дәүләт мәгариф оешмалары көндезге уку бүлекләренең укучыларның бөтенроссия олимпиадасының йомгаклау этабында, укучыларның халыкара олимпиадалары, исемлеге мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланучы укучылар олимпиадалары җиңүчеләреннән һәм бүләкләнүчеләреннән булган студентлары, бердәй дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча ике һәм аннан күбрәк гомуми белем бирү фәне буенча 100 балл җыйган гомуми белем бирү оешмаларының чыгарылыш сыйныф укучылары, шулай ук WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча милли һәм дөнья чемпионатлары җиңүчеләре һәм бүләкләнүчеләре өчен (алга таба шулай ук – Татарстан Республикасы Президенты стипендияләре, укучылар олимпиадаларында җиңүчеләр һәм бүләкләнүчеләр, бердәй дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 әр балл җыйган чыгарылыш сыйныф укучылары) Татарстан Республикасы Президентының 200 стипендиясен гамәлгә куярга, шул исәптән:

Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче студентлар өчен – 100 стипендия, шулардан:

укучылар олимпиадаларында җиңүчеләр һәм бүләкләнүчеләр, бердәй дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 әр балл җыйган чыгарылыш сыйныф укучылары өчен – 67 стипендия;

WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча милли һәм дөнья чемпионатлары җиңүчеләре һәм бүләкләнүчеләре өчен – 33 стипендия;

б) Россия Федерациясенең башка субъектларыннан килгән студентлар өчен – 100 стипендия, шулардан:

укучылар олимпиадаларында җиңүчеләр һәм бүләкләнүчеләр, шулай ук бердәй дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 әр балл җыйган чыгарылыш сыйныф укучылары өчен – 67 стипендия;

WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча милли һәм дөнья чемпионатлары җиңүчеләре һәм бүләкләнүчеләре өчен – 33 стипендия.»;

б) 3 пунктта «укучылар олимпиадалары» сүзләреннән соң «, бердәй дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 әр балл җыйган гомуми белем бирү оешмаларының чыгарылыш сыйныф укучылары, шулай ук WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча милли һәм дөнья чемпионатлары җиңүчеләре һәм бүләкләнүчеләре» сүзләрен өстәргә;

в) 6 пунктта «укучылар олимпиадалары» сүзләреннән соң «, бердәй дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 әр балл җыйган гомуми белем бирү оешмаларының чыгарылыш сыйныф укучылары, шулай ук WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча милли һәм дөнья чемпионатлары җиңүчеләре һәм бүләкләнүчеләре» сүзләрен өстәргә;

г) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирү дәүләт мәгариф оешмалары көндезге уку бүлекләренең укучылар олимпиадалары җиңүчеләреннән һәм бүләкләнүчеләреннән булган студентлары өчен Татарстан Республикасы Президенты стипендияләре турында нигезләмәдә:

атамасында «, бердәй дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 әр балл җыйган гомуми белем бирү оешмаларының чыгарылыш сыйныф укучылары, шулай ук WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча милли һәм дөнья чемпионатлары җиңүчеләре һәм бүләкләнүчеләре» сүзләрен өстәргә;

1 һәм 2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирү дәүләт мәгариф оешмалары көндезге уку бүлекләренең укучыларның бөтенроссия олимпиадасының йомгаклау этабында, укучыларның халыкара олимпиадалары, исемлеге мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланучы укучылар олимпиадалары җиңүчеләреннән һәм бүләкләнүчеләреннән булган студентлары, бердәй дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча ике һәм аннан күбрәк гомуми белем бирү фәне буенча 100 әр балл җыйган гомуми белем бирү оешмаларының чыгарылыш сыйныф укучылары, шулай ук WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча милли һәм дөнья чемпионатлары җиңүчеләре һәм

бүләкләнүчеләре өчен (алга таба шулай ук – Татарстан Республикасы Президенты стипендияләре, укучылар олимпиадаларында җиңүчеләр һәм бүләкләнүчеләр, вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы, бердәй дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 әр балл җыйган чыгарылыш сыйныф укучылары) Татарстан Республикасы Президенты стипендияләре сәләтле студентларга алар Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирү дәүләт мәгариф оешмаларында (алга таба – югары белем бирү мәгариф оешмалары) белем алган чорда өстәмә ярдәм күрсәтү максатларында гамәлгә куелды.

2. Югары белем бирү мәгариф оешмалары көндезге уку бүлекләренең укучыларның бөтенроссия олимпиадасының йомгаклау этабында, укучыларның халыкара олимпиадалары, исемлеге вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан расланучы укучылар олимпиадалары җиңүчеләреннән һәм бүләкләнүчеләреннән булган студентлары, аларның белгечлекләре һәм әзерлек юнәлешләре олимпиада профиленә туры килгәндә, бердәй дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 әр балл җыйган чыгарылыш сыйныф укучыларыннан булган студентлары, шулай ук WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча милли һәм дөнья чемпионатлары җиңүчеләре һәм бүләкләнүчеләреннән булган студентлары Татарстан Республикасы Президенты стипендияләрен дәгъвалаучы була ала.»;

3 пунктка «календарь уку-укыту графигы нигезендә арадаш аттестация йомгаклары буенча (академик бурычы яисә «канәгатьләнерлек» билгесе булмаса)» сүзләрен өстәргә;

4 пунктта:

икенче абзацка «, бердәй дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 әр балл җыйган чыгарылыш сыйныф укучылары исемлеге, шулай ук WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча милли һәм дөнья чемпионатлары җиңүчеләре һәм бүләкләнүчеләре исемлеге» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Укучыларның бөтенроссия олимпиадасы, укучыларның халыкара олимпиадалары, исемлеге вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланучы укучылар олимпиадаларының йомгаклау этабы, бердәй дәүләт имтиханы, WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча милли һәм дөнья чемпионатлары нәтиҗәләре, әлеге нәтиҗәләргә ирешелгән елдан соң килүче дүрт ел дәвамында Татарстан Республикасы Президенты стипендияләрен дәгъвалаучылар исемлегенә кертү өчен нигез булып тора.

Татарстан Республикасы Президенты стипендияләре кабаттан билгеләнми.»;

5 һәм 6 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әгәр Татарстан Республикасы Президенты стипендияләрен билгеләүгә дәгъвалаучы Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче укучылар олимпиадалары җиңүчеләреннән һәм

бүләкләнүчеләреннән булган студентлар, шулай ук бердәй дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 әр балл җыйган студентлар саны 67 дән артып китсә, дәгъвалаучылар саны бердәй дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча гомумиләштерелгән күләмдә азрак балл җыйган бүләкләнүчеләрнең тиешле санына кими.

Әгәр Россия Федерациясенең башка субъектларыннан Татарстан Республикасы Президенты стипендияләрен билгеләүгә дәгъвалаучы укучылар олимпиадалары җиңүчеләреннән һәм бүләкләнүчеләреннән булган студентлар, шулай ук бердәй дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 әр балл җыйган студентлар саны 67 дән артып китсә, дәгъвалаучылар саны бердәй дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча гомумиләштерелгән күләмдә азрак балл җыйган бүләкләнүчеләрнең тиешле санына кими.

Әгәр Татарстан Республикасы Президенты стипендияләрен билгеләүгә дәгъвалаучы Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча милли һәм дөнья чемпионатлары җиңүчеләре һәм бүләкләнүчеләреннән булган студентлар саны 33 тән артып китсә, WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча милли һәм дөнья чемпионатлары җиңүчеләренә өстенлекле хокук бирелә.

Әгәр Россия Федерациясенең башка субъектларыннан Татарстан Республикасы Президенты стипендияләрен билгеләүгә дәгъвалаучы WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча милли һәм дөнья чемпионатлары җиңүчеләре һәм бүләкләнүчеләреннән булган студентлар саны 33 тән артып китсә, WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча милли һәм дөнья чемпионатлары җиңүчеләренә өстенлекле хокук бирелә.

6. Әгәр Татарстан Республикасы Президенты стипендияләрен билгеләүгә дәгъвалаучы Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче укучылар олимпиадалары җиңүчеләреннән һәм бүләкләнүчеләреннән булган студентлар, шулай ук бердәй дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 әр балл җыйган студентлар саны 67 дән кимрәк булса, калган Татарстан Республикасы Президенты стипендияләре билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча милли һәм дөнья чемпионатлары җиңүчеләре һәм бүләкләнүчеләреннән булган студентлар арасыннан дәгъвалаучыларга бирелә.

Әгәр Россия Федерациясенең башка субъектларыннан Татарстан Республикасы Президенты стипендияләрен билгеләүгә дәгъвалаучы укучылар олимпиадалары җиңүчеләреннән һәм бүләкләнүчеләреннән булган студентлар, шулай ук бердәй дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 әр балл җыйган студентлар саны 67 дән кимрәк булса, калган Татарстан Республикасы Президенты стипендияләре билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясенең башка субъектларыннан WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча милли һәм дөнья чемпионатлары җиңүчеләре һәм

бүләкләнүчеләреннән булган студентлар арасыннан дәгъвалаучыларга бирелә.

Әгәр Татарстан Республикасы Президенты стипендияләрен билгеләүгә дәгъвалаучы Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча милли һәм дөнья чемпионатлары җиңүчеләре һәм бүләкләнүчеләреннән булган студентлар саны 33 тән кимрәк булса, калган Татарстан Республикасы Президенты стипендияләре билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче укучылар олимпиадалары җиңүчеләреннән һәм бүләкләнүчеләреннән булган студентлар, шулай ук бердәй дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 әр балл җыйган студентларга бирелә.

Әгәр Россия Федерациясенең башка субъектларыннан Татарстан Республикасы Президенты стипендияләрен билгеләүгә дәгъвалаучы WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча милли һәм дөнья чемпионатлары җиңүчеләре һәм бүләкләнүчеләреннән булган студентлар саны 33 тән кимрәк булса, калган Татарстан Республикасы Президенты стипендияләре билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясенең башка субъектларыннан укучылар олимпиадалары җиңүчеләреннән һәм бүләкләнүчеләреннән булган студентларга, шулай ук бердәй дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 әр балл җыйган студентларга бирелә.»;

8 пунктның беренче абзацында «студентның уку елы нәтиҗәләре буенча академик бурычы булса» сүзләрен «студентның арадаш аттестация йомгаклары буенча «канәгатьләнерлек» билгесе яисә академик бурычы булса» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 26 март
№ ПУ-195